**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 июнь № 394

г. Казань

2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын алга таба үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законны, Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 ел, 7 май, 601 нче Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 21 апрель, б-747 нче боерыгын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2016 – 2018 елларга Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын алга таба үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Планда каралган чараларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүче федераль башкарма хакимият органнарының һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлар органнарының территориаль органнарына, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә – дәүләт учреждениесенә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле

үзидарә органнарына Планда каралган чараларны тормышка ашыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. 2016 елда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 ел, 21 апрель, б-747 нче боерыгы белән расланган 2016 – 2018 елларга «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү системасын алга таба үстерү буенча чаралар планының 11 нче пунктында каралган эшмәкәрлек субъектларына дәүләт, муниципаль, өстәмә (иярчен) хезмәтләр күрсәтүгә юнәлдерелгән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру буенча пилот проектында (алга таба – Пилот проекты) катнашырга.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасында Пилот проектын үткәрү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\394.docx